**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 22 июлендәге 2335 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 31 декабрендәге 4723 номерлы «“Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” максатчан программасы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы «“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы «“Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү” дәүләт программасын раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 11 октябрендәге 877 номерлы «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 31 декабрендәге 4723 нче номерлы «“Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” максатчан программасы турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 31 гыйнварындагы 182 номерлы, 2018 елның 25 апрелендәге 1612 номерлы, 2018 елның 13 ноябрендәге 5808 номерлы, 2019 елның 14 июнендәге 2171 номерлы, 2019 елның 7 августындагы 2833 номерлы, 2019 елның 4 октябрендәге 3567 номерлы, 2019 елның 19 декабрендәге 4553 номерлы, 2020 елның 5 июнендәге 1603 номерлы, 2021 елның 18 июнендәге 1509 номерлы, 2021 елның 18 декабрендәге 3255 номерлы, 2022 елның 18 маендагы 1452 номерлы, 2024 елның 20 февралендәге 563 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарның кушымтасын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 31 декабрендәге 4723 номерлы «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасы турында»гы карарына кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 22 июлендәге
2335 номерлы карарына
кушымта

**«Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү»**
**максатчан программасы**

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы «“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында»гы карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы «“Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү” дәүләт программасын раслау турында»гы карары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 11 октябрендәге 877 номерлы «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында»гы карары |
| Программаны төп эшләүче | Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның төп максаты – билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә торак проблемаларын хәл итүдә өстәмә дәүләт ярдәме күрсәтү.<br>Программаның төп бурычлары түбәндәгеләр:<br>- Программада катнашучы яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләүләр (алга таба –социаль түләүләр) бирүне тәэмин итү;<br>- яшь гаиләләрнең үз акчаларын, банкларның һәм башка оешмаларның, шул исәптән торак сатып алу яисә шәхси |

| | |
|---|---|
| | торак төзү өчен ипотека торак кредитлары һәм заемнар бирә торган оешмаларның өстәмә финанс чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру |
| Программаны гамәлгә ашыру вакытлары һәм этаплары | 2024-2027 еллар |
| Программаны башкаручы | - Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе;<br>- Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре;<br>- стандарт торак бирүгә вәкаләтле оешмалар һәм федераль дәрәҗәдә билгеләнгән критерийлар нигезендә сайлап алынган банклар |
| Программаны финанслау чыганаклары | - Федераль бюджет акчалары;<br>- Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;<br>- җирле бюджет акчалары;<br>- банклар һәм башка оешмалар, шул исәптән яшь гаиләләргә торак сатып алу яисә шәхси торак төзү өчен ипотека торак кредитлары һәм заемнар бирә торган оешмалар акчалары;<br>- яшь гаиләләрнең сатып алына торган торак яисә төзелә торган шәхси торак хакын өлешчә түләү өчен тотыла торган үз акчалары |

## I. Программаның максатлары, бурычлары, принциплары һәм аны гамәлгә ашыру сроклары

Программаның төп максаты – билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү юлы белән торак проблемаларын хәл итүдә өстәмә дәүләт ярдәме күрсәтү.

Программаның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Программада катнашучы яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирүне тәэмин итү;

- яшь гаиләләрнең торак сатып алуга яисә шәхси торак төзүгә үз акчаларын, банкларның һәм башка оешмаларның, шул исәптән ипотека торак кредитлары һәм заемнары бирүче оешмаларның өстәмә финанс чараларын җәлеп итү өчен шартлар тудыру.

Программада катнашучы яшь гаиләләр стандарт торак сатып алу өчен вәкаләтле оешмаларга мөрәҗәгать итә ала.

Программаны гамәлгә ашыруның төп принциплары түбәндәгеләр:

- яшь гаиләләр программасында катнашуның ирекле булуы;

- яшь гаиләне закон нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану;

- яшь гаиләнең торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең социаль түләү күләменнән артып китә торган өлешен түләү өчен җитәрлек акчалары булу;

- яшь гаиләләр өчен Программа кысаларында федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан торак шартларын яхшыртуга бирелә торган акчалар исәбеннән ярдәм алу хокукын гамәлгә ашыру мөмкинлеге бер генә тапкыр бирелә.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2024-2027 еллар.

## II. Программа чаралары системасы

Программа чаралары системасы федераль, төбәк һәм муниципаль дәрәҗәләрдә гамәлгә ашырыла.

Федераль һәм төбәк дәрәҗәсендә оештыру чаралары «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе субъектларына торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү» федераль проектының һәм «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проектының яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча чараларын гамәлгә ашыруны күздә тота.

Казан шәһәрендә муниципаль дәрәҗәдә оештыру чаралары түбәндәгеләрне күздә тота:

- яшь гаиләләрне законда билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип тану;

- яшь гаиләләрне Программада катнашучылар итеп тану;

- Программада катнашучы яшь гаиләләрне исәпкә алуны оештыру;

- планлаштырыла торган елда социаль түләү алу теләген белдергән яшь

гаиләләрнең исемлеген ел саен төзү;

- Программаның максатларын һәм бурычларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итү;

- социаль түләү алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләргә тиешле елда таныклык алу өчен документлар тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә юллау, шулай ук әлеге таныклык буенча бирелә торган социаль түләүне алу һәм куллану тәртибен һәм шартларын аңлату;

- яшь гаиләләргә билгеләнгән тәртиптә торак сатып алуга таныклыклар бирү;

- Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформада Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип һәм күләм нигезендә һәм Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар буенча торак шартларын яхшырту өчен яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итү;

- Программа чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджет акчаларын бүлеп бирүгә гаризалар формалаштыру һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына (алга таба – Программаның дәүләт заказчысы) җибәрү;

- Программада катнашучы яшь гаиләнең бирелгән таныклыкны алмаштыруны таләп иткән шартлары барлыкка килгәндә, мондый алмаштыруны таләп иткән шартларны күрсәтеп һәм әлеге шартларны (таныклыкны югалту (урлату) яисә бозу, яшь гаиләгә таныклыкны билгеләнгән срокта банкка тапшырырга мөмкинлек бирмәгән нигезле сәбәпләр) раслаучы документларны теркәп, яшь гаилә тарафыннан язылган гариза буенча таныклыкны алмаштыру;

- Программасының дәүләт заказчысына социаль түләүләр бирүгә тиешле бюджетлардан бүлеп бирелә торган акчаларны үзләштерү турында үсә бару рәвешендә һәм хисап елы өчен тулаем хисап тапшыру.

Яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләүләр бирү тәртибе Программага 1 номерлы кушымта белән билгеләнә.

Кредит алырга мөмкинлек бирә торган җитәрлек керемнәре булган яки торак сатып алу яисә шәхси торак төзелеше объектын төзү өчен бирелә торган социаль түләү күләменнән артып китә торган өлештә торак өчен исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен башка акчалары булган яшь гаиләне тану тәртибе һәм шартлары программага 2 номерлы кушымта белән билгеләнә.

Яшь гаиләләр исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе Программага 3 номерлы кушымта белән билгеләнә.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслауның төп чыганаклары түбәндәгеләр:

- федераль бюджет акчалары;
- Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;
- җирле бюджет акчалары;
- банклар һәм башка оешмалар, шул исәптән яшь гаиләләргә торак сатып алу яисә шәхси торак төзү өчен ипотека торак кредитлары һәм заемнар бирә торган оешмалар акчалары;
- яшь гаиләләрнең сатып алына торган торак яисә төзелә торган шәхси торак бәясен өлешчә түләү өчен кулланыла торган үз акчалары.

## IV. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаны гамәлгә ашыру механизмы Программада катнашучы яшь гаиләләргә социаль түләүләр бирү юлы белән торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтүнең өстәмә чараларын күрсәтүне күздә тота.

Торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләү Программага кушымтада китерелгән кагыйдәләр нигезендә бирелә һәм файдаланыла.

Социаль түләү бирү шарты булып яшь гаиләнең торакны сатып алу (төзү) өчен өстәмә үз акчалары яисә кредит шартнамәсе (заем шартнамәсе) буенча, шул исәптән торак урынын төзү яисә сатып алу өчен кирәкле ипотека торак килешүе буенча алынган акчалары булу тора. Өстәмә акчалар сыйфатында яшь гаилә тарафыннан шулай ук ана (гаилә) капиталы акчалары (акчаларының бер өлеше) файдаланылырга мөмкин.

Социаль түләүләрне яшь гаиләгә җиткерү механизмы сыйфатында яшь гаиләнең Программаны гамәлгә ашыруда катнашуы турында карар кабул иткән Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе тарафыннан бирелә торган, торак урын сатып алу яисә шәхси торак йорт төзү өчен социаль түләү алуга хокук турындагы таныклык (алга таба – таныклык) кулланылачак. Алынган таныклыкны аның хуҗасы социаль түләүләр бирүгә каралган акчаларга хезмәт күрсәтү өчен Программаның дәүләт заказчысы тарафыннан сайлап алынган банкка тапшыра. Анда яшь гаилә әгъзасы исеменә социаль түләүне алу өчен билгеләнгән банк счеты ачыла. Яшь гаилә – таныклык хуҗасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан банк белән банк счеты шартнамәсен төзи.

## V. Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге бюджет акчаларыннан файдаланып торак шартларын яхшырткан яшь гаиләләр саны булып торган индикатор нигезендә бәяләнәчәк.

«Казан шәһәрендә яшь
гаиләләрне торак белән тәэмин
итү» максатчан программасына
1 номерлы кушымта

**«Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләре**

1.«Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын (алга таба – Программа) гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләүләр бирүнең әлеге кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе субъектларына торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү» федераль проектын һәм «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләүләр бирү һәм алардан файдалану кагыйдәләре белән билгеләнгән чараларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән.

Кагыйдәләр яшь гаиләләргә вәкаләтле оешмалар һәм сайлап алынган банклар аша торак сатып алу яки шәхси торак йорт төзү өчен социаль түләүләр бирү тәртибен билгели.

Социаль түләүләр түбәндәгечә җибәрелергә мөмкин:

а) торак урынны сату-алу шартнамәсе бәясен түләү өчен (сату-алу шартнамәсе бәясен түләү вәкаләтле оешма белән торак урынны беренчел торак базарында сатып алу шартнамәсе бәясе составында каралган очраклардан тыш);

б) торак йорт төзелешенә төзелеш подряды шартнамәсе бәясен түләү өчен;

в) пай кертемен тулы күләмдә кертү хисабына соңгы түләүне (аны түләгәннән соң торак урын яшь гаилә милкенә күчә) башкару өчен (әгәр яшь

гаилә яки яшь гаиләдәге ир белән хатынның берсе торак, торак-төзелеш, торак тупланма кооперативы әгъзасы булса);

г) сату-алу шартнамәсе буенча торак урын сатып алуга яисә торак йорт төзүгә торак кредиты, шул исәптән ипотека кредиты яисә торак заемы (алга таба – торак кредиты) алган очракта, беренчел кертемне түләү өчен;

д) беренчел торак базарында яшь гаилә мәнфәгатьләрендә торак урын сатып алуга вәкаләтле оешма белән шартнамә бәясен түләү өчен, шул исәптән торак урынны сату-алу шартнамәсе бәясен түләү өчен (вәкаләтле оешма белән шартнамәдә каралган очракларда) һәм (яисә) әлеге оешма хезмәтләренә түләү өчен;

е) төп бурыч суммасын (төп бурыч суммасының бер өлешен) каплау һәм торак урын сатып алуга яисә торак йорт төзүгә торак кредиты буенча яисә торак урын сатып алуга яисә торак йорт төзүгә элек бирелгән торак кредитын каплау өчен кредит (заем) буенча процентлар түләү өчен (әлеге торак кредитлары яисә элек бирелгән торак кредитын каплауга кредитлар (заемнар) буенча йөкләмәләрне үз вакытында башкармаган өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан кала);

ж) өлешкә кереп төзү объекты буларак 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешкә кереп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль законның 4 статьясындагы 4 өлешенең 5 пунктында билгеләнгән өлешкә кереп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү шартларының берсенә туры килгән торак урын күздә тотылган өлешкә кереп төзүдә катнашу шартнамәсе (алга таба – өлешкә кереп төзүдә катнашу шартнамәсе) бәясен түләү өчен яисә өлешкә кереп төзүдә катнашу шартнамәсе буенча өлешкә кереп төзүдә катнашучы тарафыннан таләпләр хокукларын бирү шартнамәсе (алга таба – өлешкә кереп төзүдә катнашу хокукларын бирү шартнамәсе буенча таләпләр хокукларын бирү шартнамәсе) бәясен түләү өчен;

з) өлешкә кереп төзүдә катнашу шартнамәсе бәясен түләүгә, өлешкә кереп төзүдә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларын бирү шартнамәсе бәясен түләүгә торак кредиты алганда, беренчел кертемне түләү өчен;

и) өлешкә кереп төзүдә катнашу шартнамәсе бәясен түләүгә яисә өлешкә кереп төзүдә катнашу шартнамәсе буенча таләпләр хокукларын бирү шартнамәсе бәясен түләүгә торак кредиты буенча яки өлешкә кереп төзүдә катнашу шартнамәсе бәясен түләүгә яисә өлешкә кереп төзүдә катнашу

шартнамәсе буенча таләпләр хокукларын бирү шартнамәсе бәясен түләүгә элек бирелгән торак кредитын каплауга кредит (заем) буенча төп бурыч суммасын (төп бурычның бер өлешен) каплау һәм процентлар түләү өчен (әлеге торак кредитлары яисә элек бирелгән торак кредитын каплауга кредитлар (заемнар) буенча йөкләмәләрне үз вакытында башкармаган өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан кала);

2. Программада катнашучы яшь гаиләнең социаль түләү алуга хокукы исемле документ – торак урын сатып алуга яисә торак йорт төзүгә социаль түләү алуга хокук турындагы, кыйммәтле кәгазь булып саналмый торган таныклык (алга таба – таныклык) белән раслана.

Социаль түләү якын туганнарыннан (иреннән (хатынынннан), бабасыннан (әбисеннән), оныкларыннан, ата-аналарыннан (шул исәптән уллыкка алучылардан), балаларыннан (шул исәптән уллыкка алынганнарыннан), тулы туганнарыннан һәм тулы булмаган туганнарыннан) торак урын сатып алу өчен файдаланыла алмый.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе (алга таба – Идарә) карары нигезендә яшь гаилә планлаштырыла торган елда социаль түләү алырга теләк белдергән яшь гаиләләр исемлегенә кертелә һәм әлеге оешма тарафыннан Федераль дәүләт программасында билгеләнгән форма буенча таныклык бирелә.

4. Таныклыкның гамәлдә булу вакыты таныклыкта күрсәтелгән, таныклык бирелгән көннән алып 7 айдан артык түгел.

5. Программада Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче яшь гаилә, шул исәптән бер һәм аннан артык баласы булган, ир белән хатынның берсе Россия Федерациясе гражданины булмаган яшь гаилә, шулай ук Россия Федерациясе гражданины булып торучы яшь атадан (анадан) һәм бер яки аннан артык баладан торган тулы булмаган гаилә катнашырга мөмкин, шул ук вакытта балалар ир яисә хатынның яисә атаның (ананың) түбәндәге шартларга туры килә торган тулы булмаган гаиләсе карамагында булырга тиеш:

а) ир яисә хатынның яисә тулы булмаган гаиләдәге ата яки ананың берсенең яше 35 тән артмавы;

б) яшь гаилә Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә торак урынына (торак шартларын яхшыртуга) мохтаҗ дип танылган;

в) гаиләнең кредит алырга мөмкинлек бирә торган керемнәре булу яисә торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең бирелә торган социаль түләү күләменнән артып китә торган өлешен түләргә җитәрлек башка акчалары булу.

6. Кагыйдәләргә туры китереп, торак урынга мохтаҗлар дигәндә 2005 елның 1 мартына кадәр торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә куелган яшь гаиләләр, шулай ук Идарә тарафыннан 2005 елның 1 мартыннан соң, торак урынга мохтаҗ буларак исәпкә куелу-куелмавына бәйсез рәвештә, гражданнарны социаль наем килешүләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ дип тану өчен Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясы белән билгеләнгән шундый ук нигезләр буенча торак урыннарына (торак шартларын яхшыртуга) мохтаҗлар буларак танылган яшь гаиләләр аңлашыла.

Яшь гаиләнең торак урынның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен билгеләгәндә, яшь гаилә әгъзалары тарафыннан социаль наем шартнамәләре буенча биләп торган, яшәргә яраклы барлык торак урыннарның гомуми мәйданының, шулай ук яшь гаилә әгъзаларының милке хокукында булган торак урыннарының һәм (яки) торак урынның (торак урыннарның) бер өлешенең суммар күләме исәпкә алына.

Элек бирелгән торак кредитын каплауга социаль түләү кулланылган очракта яшь гаиләнең торак урынының гомуми мәйданы белән тәэмин ителү дәрәҗәсен билгеләгәндә торак кредиты акчалары хисабына алынган (төзелгән), аның буенча йөкләмәләр тулысынча үтәлмәгән, яисә элек алынган торак кредитын каплауга кредит (займ) буенча йөкләмәләр үтәлмәгән торак урын исәпкә алынмый.

Яшь гаиләне торак урынына мохтаҗ дип тануны кире кагу Россия Федерациясе Торак кодексының 54 статьясы нигезендә билгеләнә.

Торак урынга мохтаҗ дип тану өчен яшь гаилә Идарәгә шәхси мөрәҗәгать юлы белән яисә электрон рәвештә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» (www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (www.uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы), яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә (алга таба – күпфункцияле үзәк) яшь гаиләне Программада катнашу мөмкинлеге өчен торак урынга мохтаҗ дип тану турында гариза бирә [Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә – ике нөсхәдә (гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушып бирелгән документларны күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә бер нөсхә кире кайтарыла)] һәм Кагыйдәләрнең 2 номерлы кушымтасы нигезендә документлар тапшыра.

Идарә документларда булган белешмәләрне тикшерү эшен оештыра, ведомствоара запрослар җибәрә һәм документлар тапшырылган көннән

22 эш көне эчендә яшь гаиләне торак урынына мохтаҗ дип тану яки танымау турында карар кабул итә. Кабул ителгән карар турында Идарә яшь гаиләгә гаризада күрсәтелгән ысул белән өч эш көне эчендә хәбәр итә.

7. Социаль түләүдән файдаланып торак шартларын яхшырту хокукы Программа кысаларында яшь гаиләгә бер генә тапкыр бирелә. Программада катнашу ирекле.

8. Социаль түләү түбәндәге күләмдә бирелә:

а) торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең Кагыйдәләр нигезендә билгеләнә торган 30 проценты – балалары булмаган яшь гаиләләр өчен;

б) торакның Кагыйдәләр нигезендә билгеләнә торган исәп-хисап (уртача) бәясенең 35 проценты – бер һәм аннан артык баласы булган яшь гаиләләр, шулай ук бер ата-анадан һәм бер һәм аннан артык баласы булган тулы булмаган яшь гаиләләр өчен.

Социаль түләү пай кертемен тулысынча түләү өчен соңгы түләүне түләүгә кулланылган очракта, аның күләме әлеге пункт нигезендә билгеләнә һәм пайның калган өлешен түләү буенча бурыч өлеше суммасы белән чикләнә.

Социаль түләү бурычның төп суммасын түләүгә һәм торак кредитлары, шул исәптән ипотека кредитлары яисә торак урын сатып алуга яисә торак йорт төзүгә алынган торак заемнары буенча процентлар, әлеге кредитлар яисә заемнар буенча йөкләмәләр вакытында башкарылмаган өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан кала, түләүгә файдаланылган очракта әлеге пункт нигезендә билгеләнә һәм төп бурычның калган суммасы һәм ипотека торак кредитыннан яисә заемнан файдаланган өчен процентларны, әлеге кредитлар яисә заемнар буенча йөкләмәләр вакытында башкарылмаган өчен башка процентлардан, штрафлардан, комиссияләрдән һәм пенялардан кала, түләү буенча бурычның калган суммасы белән чикләнә.

9. Социаль түләү күләме Кагыйдәләрнең 12 пункты нигезендә билгеләнгән торак урынның гомуми мәйданы күләменнән, яшь гаилә әгъзалары саныннан һәм гомуми торак мәйданының 1 кв.м бәясенең яшь гаилә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча нормативыннан чыгып исәпләнә. Социаль түләү күләмен исәпләү өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча гомуми торак мәйданының 1 кв.м бәясенең нормативы Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр бирелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган Татарстан

Республикасы буенча гомуми торак мәйданының 1 кв.м уртача базар бәясеннән түбәнрәк билгеләнә.

10. Ир яки хатынның берсе Россия Федерациясе гражданы булмаган яшь гаилә өчен социаль түләү күләме, торак урынның, Россия Федерациясе гражданнары булган гаилә әгъзаларын да исәпкә алып, төрле сандагы гаиләләр өчен билгеләнгән гомуми мәйданы күләменнән чыгып, Кагыйдәләрнең 9 пункты нигезендә исәпләнә.

11. Торак урынның социаль түләү күләмен билгеләүдә исәпкә алына торган гомуми мәйданы күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

- ике кешелек гаилә өчен (яшь ир белән хатын яки бер яшь ата-ата һәм бала) – 42 кв.м;

- яшь ата-анадан кала, бер һәм аннан да күбрәк баладан торган өч һәм аннан күбрәк кешелек гаилә өчен (яки бер яшь ата-ана һәм ике һәм аннан да күбрәк балалардан торган гаилә өчен) – һәр кешегә 18 кв.м.

12. Торакның социаль түләү күләмен исәпләгәндә кулланыла торган исәп-хисап (уртача) бәясе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$СтЖ = Н \cdot РЖ,$$ монда

СтЖ – торакның социаль түләү күләмен исәпләгәндә кулланыла торган исәп-хисап (уртача) бәясе;

Н – торакның гомуми мәйданының Кагыйдәләрнең 9 пунктында билгеләнгән таләпләр нигезендә билгеләнә торган 1 кв.м бәясе нормативы;

РЖ – торак урынның Кагыйдәләрнең 11 пункты нигезендә билгеләнә торган гомуми мәйданы күләме.

13. Социаль түләү күләме Программаның дәүләт заказчысы тарафыннан социаль түләү алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлекләрен раслау көненә исәпләнә, таныклыкка языла һәм ул гамәлдә булган вакыт дәвамында үзгәрешсез кала.

14. Программада катнашучы дип тану өчен яшь гаилә Идарәгә түбәндәгеләрне тапшыра:

а) Кагыйдәләргә 3 номерлы кушымтадагы форма нигезендә гариза;

б) гаиләнең һәр әгъзасының шәхесен таныклый торган документларының күчермәләре;

в) өйләнешү турындагы таныклык күчермәсе (тулы булмаган гаиләгә кагылмый);

г) яшь гаиләне торак урыннарга мохтаҗ дип тануны раслый торган документ;

д) яшь гаиләне керемнәре булган дип тануны раслый торган, кредит алырга мөмкинлек бирә торган документлар яисә торакның исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен бирелә торган социаль түләү күләменнән артыграк өлештә башка акчалар.

Кредит алырга мөмкинлек бирә торган җитәрлек керемнәре булган яки торак сатып алу яисә шәхси торак төзелеше объектын төзү өчен бирелә торган социаль түләү күләменнән артып китә торган өлештә торак өчен исәп-хисап (уртача) бәясен түләү өчен башка акчалары булган яшь гаиләне тану тәртибе һәм шартлары программага 2 номерлы кушымта белән билгеләнә.

е) гаиләнең һәр әгъзасының шәхси (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүен раслый торган документның күчермәсе;

ж) яшь гаиләдәге ир белән хатынның берсенең яки икесенең дә яисә тулы булмаган гаиләдәге ананың (атаның) берсенең Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә (алга таба – махсус хәрби операция) катнашуын раслый торган документның күчермәсе (булган очракта).

15. Идарә Кагыйдәләрнең 14 пунктында күрсәтелгән документлардагы белешмәләрне тикшерү эшен оештыра һәм әлеге документлар тапшырылган көннән алып 5 эш көне эчендә яшь гаиләне Программада катнашучы итеп тану яисә танудан баш тарту турында карар кабул итә. Кабул ителгән карар турында Идарә яшь гаиләгә гаризада күрсәтелгән ысул белән өч эш көне эчендә хәбәр итә.

16. Яшь гаиләне Программада катнашучы дип тануны кире кагу өчен нигезләр:

а) яшь гаиләнең Кагыйдәләрнең 5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

б) Кагыйдәләрнең 14 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки тулысынча тапшырмау;

в) тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы;

г) ана (гаилә) капиталы акчаларыннан (акчаларының бер өлешеннән) кала, социаль түләүдән яисә федераль бюджет акчалары хисабына дәүләт ярдәменең башка формаларыннан, шулай ук балалары булган гаиләләргә 2019 елның 3 июлендәге 157-ФЗ номерлы «Балалары булган гаиләләргә ипотека торак кредитлары (заемнар) буенча йөкләмәләрне каплау өлешендә дәүләт ярдәме чаралары турында һәм “Гражданлык хәле актлары турында”гы федераль законның 13.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль законда каралган ипотека торак кредитлары буенча йөкләмәләрне каплау

өлешендә дәүләт ярдәме чараларын файдаланып, элек гамәлгә ашырылган торак шартларын яхшырту хокукы.

Программада катнашу турындагы гариза белән кабат мөрәҗәгать итү Кагыйдәләрнең 16 пунктында каралган кире кагу өчен нигезләр бетерелгәннән соң рөхсәт ителә.

17. Идарә яшь гаиләләрне Программада катнашучылар исемлегенә кертү турында Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасарының боерыгы кабул ителгәч, яшь гаиләләр Программада катнашучылар дип танылган хронологик тәртиптә Программада катнашучылар исемлегенә кертеп, Программада катнашучылар исемлеген төзи. Программада катнашучылар дип бер үк көнне танылган яшь гаиләләр, шулай ук ир белән хатынның берсенең яки икесенең дә яисә тулы булмаган гаиләдәге ананың (атаның) берсе махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) яшь гаиләләр, документлар тапшыру датасыннан һәм вакытыннан чыгып, программада катнашучылар исемлегенә кертеләләр.

18. Идарә ел саен 1 майдан 20 майга кадәр чорда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны һәм Программада катнашучы дип танылган яшь гаиләләрнең түләү сәләтен тикшерә. Идарә планлаштырыла торган елның алдагы елының 1 июненә кадәр Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә планлаштырылган елда социаль түләү алырга теләк белдергән яшь гаиләләрнең җыелма исемлеген төзи һәм әлеге исемлекне Программаның дәүләт заказчысы соратуы буенча тапшыра.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны һәм түләү сәләтен раслау өчен яшь гаилә 1 майга кадәр Идарәгә Кагыйдәләрнең 4 номерлы кушымтасында күрсәтелгән гаризаны һәм Кагыйдәләрнең 5 номерлы кушымтасында күрсәтелгән документларны тапшыра.

Кагыйдәләрнең 14 пунктында каралган документларны Идарәгә тапшырганда яшь гаилә күрсәткән белешмәләр үзгәргән очракта (шул исәптән гаилә составы, даими яшәү урыны, мөлкәти хәле үзгәргән очракта), яшь гаилә эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә мондый үзгәрешләрнең барлыкка килүе турында идарәгә язма рәвештә хәбәр итә. Идарә хәбәрнамә алынганнан соң эш көннәрдә исәпләнә торган 10 көн эчендә кабат әлеге яшь гаиләнең торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыгын һәм түләү сәләтен билгеләү эшен башкара.

Гаилә таркалган очракта, Программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәптә, торак шартларын яхшыртуга

мохтаҗлыгын һәм түли алу мөмкинлеге булуын раслау шартында, Идарә карары буенча тулы булмаган яшь гаилә кала.

Ел саен тикшерү яисә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны кабат билгеләү һәм түләү сәләтен кабат билгеләү барышында яшь гаилә Программада катнашу өчен торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлыкны расламаса һәм (яисә) яшь гаиләне Программада катнашучылар составыннан төшереп калдыру өчен нигезләрнең берсе ачыкланса, Идарә 10 көн эчендә мондый тикшерү тәмамланган яисә тиешле нигезләрне ачыклаган көннән яшь гаиләне Программада катнашучылар составыннан төшереп калдыру турында карар (алга таба – карар) кабул итә. Карарда Программада катнашучылар составыннан төшереп калдыру өчен нигезләр булырга тиеш. Карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә әлеге карар кабул ителгән яшь гаиләгә тапшырыла яки җибәрелә.

Әгәр Программада катнашучылар составыннан чыгарылганнан соң яшь гаиләнең Программада катнашучы итеп танылу хокукы яңадан барлыкка килсә, Программада катнашучыны кабат тану гомуми тәртиптә һәм Программада катнашучы итеп тануның яңа датасы белән башкарыла.

19. Программада катнашучылар составыннан түбәндәгеләр төшереп калдыру өчен нигез була:

а) Программада катнашучылар составыннан төшереп калдыру турында яшь гаилә тарафыннан гариза бирү;

б) Кагыйдәләрнең 5 пунктындагы социаль түләү алуга хокукны яшь гаиләгә бирә торган нигезләрнең берсен югалту;

в) башка муниципаль берәмлеккә даими яшәргә күчеп китү;

г) тапшырылган яки сорату буенча алынган документларда дөреслеккә туры килми торган һәм исәпкә алу өчен нигез булып торган мәгълүматларны ачыклау, шулай ук исәпкә алу мәсьәләсен хәл иткәндә Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсендәге вазифаи затларның законсыз гамәлләрен ачыклау;

д) ана (гаилә) капиталы акчаларыннан (акчаларының бер өлешеннән) кала, социаль түләүдән яисә федераль бюджет акчалары хисабына дәүләт ярдәменең башка формаларыннан, шулай ук балалары булган гаиләләргә 2019 елның 3 июлендәге 157-ФЗ номерлы «Балалары булган гаиләләргә ипотека торак кредитлары (заемнар) буенча йөкләмәләрне каплау өлешендә дәүләт ярдәме чаралары турында һәм “Гражданлык хәле актлары турында”гы федераль законның 13.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль законда каралган ипотека торак кредитлары буенча йөкләмәләрне каплау

өлешендә дәүләт ярдәме чараларын файдаланып, гамәлгә ашырылган торак шартларын яхшырту хокукы.

20. Планлаштырылган елда социаль түләүне алу теләген белдергән Программада катнашучы яшь гаиләләр исемлеге Программада катнашучы яшь гаиләне тану датасын исәпкә алып төзелә. Беренче чиратта күрсәтелгән исемлекләргә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак 2005 елның 1 мартына кадәр исәпкә куелган яшь гаиләләр, өч һәм аннан да күбрәк баласы булган яшь гаиләләр, шулай ук ир белән хатынның берсенең яки икесенең дә яисә тулы булмаган гаиләдәге ананың (атаның) берсе махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) яшь гаиләләр кертелә.

Программаның дәүләт заказчысы планлаштырылган елда социаль түләүне алу теләген белдергән чарада катнашучы яшь гаиләләрнең җыелма исемлеген төзи. Чарада катнашучы яшь гаиләләрнең җыелма исемлегенә үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы буенча планлаштырыла торган елда социаль түләү алырга теләк белдергән яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чарасында катнашучы яшь гаиләләр исемлекләренә һәм тиешле елда Татарстан Республикасы буенча яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру кысаларында торак урын сатып алу яисә шәхси торак төзелеше объектын төзү өчен социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлегенә, федераль бюджеттан финанслау шартларында кергән субсидияләрне дә кертеп, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары чикләрендә үзгәрешләр кертү тәртибе Программаның 3 номерлы кушымтасы белән билгеләнә.

Программаның дәүләт заказчысы тиешле елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлеген раслау датасыннан алып 10 календарь көн эчендә тиешле елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләрнең расланган исемлегеннән өземтәләрне Идарәгә җиткерә.

Идарә тиешле елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы Программада катнашучы яшь гаиләләргә, аларны тиешле елда социаль түләүләргә дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлегенә кертү мәсьәләсе буенча Программаның дәүләт заказчысы карарын (Бердәм портал яки Республика порталы ярдәмендә язмача яки электрон формада) җиткерә.

21. Яшь гаиләләр планлаштырыла торган елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлекләреннән түбәндәге нигезләр буенча төшереп калдырыла:

а) яшь гаилә тарафыннан исәпкә баскан урыны буенча планлаштырыла торган елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлегеннән төшереп калдыру турында гариза бирелгән;

б) Кагыйдәләрнең 19 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча;

в) торакның исәп-хисап (уртача) бәясенең бирелә торган социаль түләү күләменнән артыграк өлешен түләү өчен җитәрлек керемнәре яисә башка акчалары булмау;

г) яшь гаиләнең әлеге Кагыйдәләрнең 6 пунктында каралган таләпләргә туры килмәвенә китергән аерылышу;

д) Кагыйдәләрнең 23 пункты нигезендә таныклык алу өчен яшь гаилә тарафыннан кирәкле документларны тапшырмау.

22. Татарстан Республикасы бюджетыннан социаль түләүләр бирү өчен билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирүгә каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәрнамә алганнан соң биш эш көне эчендә Идарә, хәбәрнамә җибәрү фактын һәм көнен расларга мөмкинлек бирүче ысул белән, тиешле елда социаль түләү алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләргә таныклык алу өчен документлар тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә җибәрә, шулай ук әлеге таныклык буенча бирелә торган социаль түләүне алу һәм файдалану тәртибен һәм шартларын аңлата.

23. Таныклык алу өчен яшь гаилә – тиешле елда социаль түләү алуга дәгъва кылучы, таныклык алу өчен документлар тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә алганнан соң 15 эш көне эчендә Идарәгә мондый таныклыкны бирү турында гариза (ирекле рәвештә) һәм Кагыйдәләргә 5 номерлы кушымтада күрсәтелгән документларны җибәрә.

Гаризада яшь гаилә социаль түләүне Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда алуга язмача ризалык бирә.

Күрсәтелгән документлар Идарәгә шәхсән мөрәҗәгать итү юлы белән яисә электрон рәвештә Бердәм портал яисә Республика порталы аша тапшырыла. Документлар электрон рәвештә тапшырылган очракта, документлар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрдән файдалану өчен мөрәҗәгать иткәндә куллану рөхсәт ителә торган электрон имза төрләре турында»гы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрдән файдалану өчен мөрәҗәгать иткәндә куллану рөхсәт ителә торган электрон имза төрләрен билгеләү кагыйдәләренең 2.1 пункты нигезендә яшь гаилә әгъзасының гади электрон имзасы белән имзалана».

Идарә күрсәтелгән документлардагы белешмәләрне тикшерү эшен

оештыра.

24. Идарә таныклыкларны рәсмиләштерә һәм аларны Программаның дәүләт заказчысы тарафыннан расланган тиешле елда социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләр исемлеге нигезендә социаль түләүләр алуга дәгъва кылучы яшь гаиләләргә субсидияләр бирү елының 1 мартына кадәр тапшыра.

25. Таныклык бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- таныклык алу өчен кирәкле документларны тапшыруның Кагыйдәләрнең 23 пунктында билгеләнгән срогын бозу;

- Кагыйдәләрнең 23 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яисә тулы күләмдә тапшырмау;

- тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы;

- заем чаралары ярдәмендә сатып алынган (төзелгән) торак урынның (торак йортның) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләре кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алуга (төзүгә) социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 38 пунктындагы таләпләргә туры килмәве.

26. Программада катнашучы яшь гаиләдә социаль түләүне алу хокукы турында бирелгән таныклыкны алыштыруны таләп иткән хәлләр килеп чыкканда, яшь гаилә таныклык биргән Идарәгә аны алмаштыру турында гариза тапшыра, андый алмаштыруны таләп иткән хәлләрне күрсәтә һәм шушы хәлләрне раслый торган документларны кушып бирә. Мондый шартларга бу таныклыкның югалуы (урлау) яки бозылуы һәм яшь гаиләгә аны билгеләнгән вакытта Программада катнашучы яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр сыйфатында бирелә торган акчаларга хезмәт күрсәтү өчен сайлап алынган банкка (алга таба – банк) тапшырырга мөмкинлек бирмәгән нигезле сәбәпләр керә. Бирелгән таныклыкны алыштыру турында гариза Идарәгә язма рәвештә яисә электрон рәвештә Бердәм портал яисә Республика порталы аша тапшырыла.

Социаль түләү алу хокукы турындагы таныклыкны алыштыру турында гариза алынган көннән алып 10 эш көне эчендә әлеге таныклыкны биргән Идарә социаль түләү алу хокукы турында яңа таныклык бирә, анда алмаштырылган таныклыкта каралган социаль түләү күләме һәм калган гамәлдә булу вакытына туры килә торган гамәлдә булу вакыты күрсәтелә.

27. Социаль түләү социаль түләүне акчасыз формада алу хокукы турында таныклык хуҗасына, банкның бюджет акчаларын күчерү турындагы гаризасына нигезләнеп, банкта ачылган банк счетына тиешле акчалар күчерү юлы белән бирелә.

Социаль түләү алу хокукы турындагы таныклыкның хуҗасы аны биргән көннән алып 1 ай эчендә бу таныклыкны банкка тапшыра.

Социаль түләү алу хокукы турындагы таныклык, аны биргән көннән алып бер ай вакыт узгач, банк тарафыннан кабул ителми. Шушы вакыт узганнан соң, социаль түләү алу хокукы турында таныклыкның хуҗасы Кагыйдәләрнең 26 пунктында каралган тәртиптә әлеге таныклыкны биргән Идарәгә аны алыштыру турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Счет белән идарә итүче социаль түләүне Кагыйдәләрнең 1 пункты нигезендә куллана.

28. Идарә квартал саен, хисап аеннан соң килә торган айның 3 есенә кадәр, социаль түләүләр бирүгә бүлеп бирелгән бюджет акчаларыннан файдалану турында җыелма хисап төзи һәм, аны Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе килештергәннән соң, мәгълүматларны «Электрон бюджет» системасына кертә һәм хисап кварталыннан соң килә торган айның 10 ысына кадәр Программаның дәүләт заказчысына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча җыелма хисап тапшыра.

29. Социаль түләү Кагыйдәләрнең 1 пунктында каралган максатларга кертелгән акчаларны Программада катнашучының банк счетына банк тарафыннан күчерү турында счет хуҗасының күрсәтмәсе банк тарафыннан үтәлгән көннән Программада катнашучыга бирелгән дип санала. Күрсәтелгән акчаларны күчерү Идарә тарафыннан яшь гаиләне Программада катнашучылар составыннан төшереп калдыру өчен нигез булып тора.

Программада катнашучы яшь гаиләләрнең торак шартларын яхшырту алга таба Россия Федерациясе законнары нигезендә гомуми нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

Сатып алынган торак урын ир белән хатынның берсенә яки икесенә милек буларак рәсмиләштерелгән очракта, таныклык биргән Идарә, гариза алынган көннән алып 22 эш көне эчендә, торак урынны яки торак йортны чикләнгән хокуклардан азат иткән вакыттан соң 6 ай эчендә социаль түләү ярдәмендә сатып алынган торак урынны яки торак йортны таныклыкта күрсәтелгән барлык гаилә әгъзаларына гомуми милек буларак яңадан рәсмиләштерү турында нотариаль расланган йөкләмәнең (хисап эшенә кертелгән) күчермәсен Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына мәгълүмат

өчен җибәрә. Күрсәтелгән йөкләмәне Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына җибәрү турында хатның күчермәсе (яки нөсхәсе) хисап эшенә беркетелә.

30. Яшь гаилә нindидер сәбәп белән таныклыкның гамәлдә булу вакытында үзенә бирелгән социаль түләүне алу хокукыннан файдалана алмаган очракта, ул Идарәгә, социаль түләү чараларын күчермичә, банк счеты шартнамәсен ябу турында белешмә тапшыра һәм Программада алга таба катнашу хокукын саклап кала.

«Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренә
1 номерлы кушымта
(Форма)

Казан шәһәре Башкарма комитетының
Торак сәясәте идарәсе башлыгы

_______________________________________________
(җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)
_______________________________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А.и.(булган очракта) тулысынча)
_______________________________________________,
түбәндәге адрес буенча яшәүче:
_______________________________________________
(почта адресы тулысынча)
_______________________________________________
_______________________________________________,
e-mail: ____________________________________
элемтә өчен телефон ________________________

**гариза.**

«Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Россия Федерациясе субъектларына торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү» федераль проектының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проекты чарасында катнашу өчен торак шартларын (торак урынында) яхшыртуга түбәндәге составтагы яшь гаиләне мохтаҗ дип тануны сорыйм:

ир:
___________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган вакыты)
паспорты: сериясе ___________ № ___________, _______ елның «____»_____________
_____________________________________________________________ тарафыннан бирелгән,
_______________________________________________________ _______адресы буенча яши;

хатын:___________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган вакыты)
паспорты: сериясе ___________ № ___________, _______ елның «____»_____________
_____________________________________________________________ тарафыннан бирелгән,
_______________________________________________________ _______адресы буенча яши;

балалар: ____________________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган вакыты)

туу турында таныклык (14 яше тулган бала өчен – паспорт):

(кирәк булмаганын сызарга)

сериясе ___________ № ___________, _______ елның «____»_____________

______________________________________________________________ тарафыннан бирелгән,

__________________________________________________________ _______адресы буенча яши;

балалар___________________________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган вакыты)

туу турында таныклык (14 яше тулган бала өчен – паспорт):

(кирәк булмаганын сызарга)

сериясе ___________ № ___________, _______ елның «____»_____________

______________________________________________________________ тарафыннан бирелгән,

__________________________________________________________ _______адресы буенча яши;

балалар___________________________________________________________________________,

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган вакыты)

туу турында таныклык (14 яше тулган бала өчен – паспорт):

(кирәк булмаганын сызарга)

сериясе ___________ № ___________, _______ елның «____»_____________

______________________________________________________________ тарафыннан бирелгән,

__________________________________________________________ _______адресы буенча яши;

Ана (гаилә) капиталы чараларыннан (чаралар өлешеннән), шулай ук 2019 елның 3 июлендәге 157-ФЗ номерлы «Балалары булган гаиләләргә ипотека торак кредитлары (заемнар) буенча йөкләмәләрне каплау өлешендә дәүләт ярдәме чаралары турында һәм “Гражданлык хәле актлары турында”гы федераль законның 13.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»гы федераль закон нигезендә каралган балалары булган гаиләләргә ипотека торак кредитлары буенча йөкләмәләрне үтәү өлешендә дәүләт ярдәме чараларыннан кала, социаль түләү файдаланып, торак шартларын яхшыртуга федераль бюджет чаралары яки дәүләт ярдәменең башка формасы элегрәк минем тарафтан һәм минем гаилә әгъзалары тарафыннан торак урын алу яки төзү өчен гамәлгә ашырылмады.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә, автоматлаштырылган чаралар кулланып, шулай ук автоматлаштырылган чаралар кулланмыйча, шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә, атап әйткәндә, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга ризалык бирәбез.

Әлеге ризалык күрсәтелгән мәгълүматлар булган тиешле мәгълүматны яки документларны саклауның Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән вакыты чыкканчыга кадәр бирелә.

Гаилә әгъзалары гариза белән килешә:

| | |
|---|---|
| ____________________________________ | ______________ |
| (фамилиясе, исеме, атасының исеме) | (имза) |
